Россия Федерациясе
мөселманнары Диния нәзарәте

بسم الله الرحمن الرحيم

# ГЫЙД ӘЛ-ФИТР (УРАЗА БӘЙРӘМЕ) УҢАЕННАН РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ РӘИСЕ, МӨФТИ ШӘЕХ РАВИЛ ГАЙНЕТДИННЕҢ

# МӨРӘҖӘГАТЬНАМӘСЕ

**Мәскәү**
1 Шәүвәл 1445 һиҗри ел
10 апрель 2024 ел

بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

**Мәрхәмәтлеләрнең мәрхәмәтлесе булган Аллаһ исеме белән!**

Рәхмәте киң булган галәмнәрнең Хуҗасы, күк белән җирне бар кылучы, бар мәхлүкат тарафыннан данланучы һәм һәрнәрсәгә рәхимле Аллаһка мактау булсын! Пәйгамбәрләрнең һәм Расүлләрнең соңгысы Мөхәммәт салләллаһу галәйһи вә сәлламгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм Кыямәт көненә кадәр алар юлында булучыларга Раббыбызның рәхмәте ирешсен!

السلام عليكم ورحمة الله وبركاته

**Сезгә Аллаһы Тәгаләдән иминлек, Аның рәхмәтен һәм бәрәкәтен сорыйм!**

**Кадерле дин кардәшләрем!**

Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте исеменнән сезне, туганнарыгызны һәм якыннарыгызны динебездәге ике бөек бәйрәмнең берсе булган Ураза гаете белән котлыйм.

Аллаһы Тәгаләнең:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ
عَلَى الَّذِينَ مِنْ قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ

***«И иман китергән кешеләр! Сезгә, сездән алдагы кешеләргә фарыз ителгән кебек, ураза фарыз ителде. Шулвакыт сез Аллаһтан куркучы булырсыз»*** (*“Әл-Бәкарә” сүрәсе, 183а.*), — дигән өндәвенә буйсынып, ураза тоттык һәм әлеге мөбарәк ай дәвамында игелекле гамәлләрне күбрәк кылырга тырыштык: Коръән укыдык, өстәмә намазлар кылдык, садака тараттык, мәчетләрдә гыйбадәт кылдык.

Рамазанның мөһимлеген күрсәтеп, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәллам:

من صام رمضان إيمانا واحتسابا
غفر له ما تقدم من ذنبه

*«Кем Рамазан аенда
Аллаһ ризалыгы өчен генә
һәм әҗеренә өметләнеп ураза
тота, аның алдагы гөнаһлары гафу
ителер», — дигән* (Әл-Бохари).

Рамазан аеның бу мөбарәк көннәрендә ихластан һәм чиста күңел белән кылган гамәлләребезне кабул итүен һәм дөнья тормышында да, мәңгелек тормышта да күп санлы әҗер-саваплар бирүен сорап, Аллаһы Раббыбызга чын күңелдән дога кылабыз.

Бу изге айның уразасы камил санала, чөнки ул безнең күңел үсешен генә түгел, ә кешеләргә әхлакый яктан хезмәт итү юлы белән Аллаһка гыйбадәт кылуны да күздә тота. Әлеге тәгълимат башкалар өчен игелекле гамәлләр кылуда, аларга ягымлы булуда, мохтаҗларга һәм авыр хәлдә калучыларга, ятимнәргә һәм картларга әхлакый һәм матди яктан ярдәм күрсәтүдә күренә.

Кешеләргә хезмәт итүнең нигезе нинди генә керемгә ия булуына карамастан, һәр мөселман өчен мәҗбүри булган, Рамазан ае өчен билгеләнгән фитр садакасында чагылыш таба:

فرض رسول الله – صلى الله عليه وسلم – زكاة الفطر
طهرة للصائم مِن اللغو والرفث وطعمة للمساكين

*«Аллаһның Расүле Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәллам фитр садакасын ураза тотучыга начар һәм буш сүзләреннән чистарыну чарасы буларак, шулай ук мохтаҗларга сый буларак таратырга боерган»*
(Әбү Дауд).

Ураза аша без чистарынабыз һәм камилләшәбез. Тәүбәгә килеп һәм өмет аша, Аллаһы Тәгаләнең ихтыяры белән без аңлы рәвештә тәкъвалык һәм диндарлыкка ирешәбез. Ураза үз-үзебезгә карата гамьсезлектән һәм тирә-юньдәгеләргә карата ваемсызлыктан уята!

ما آمن بي من بات شبعانًا و جاره جائع
إلى جنبه و هو يعلم

*«Күршесе ач булып, тук килеш
йокларга яткан кеше мөэмин
түгел!»* (Әт-Тәбәрани).

Донбасста, Фәләстыйнда
һәм дөньяның башка
төбәкләрендә бер гаепсездән
кеше каны коелган заманда, без —
Россия Федерациясе мөселманнары
мохтаҗлыкта һәм авыр хәлдә калган, ураза
вакытында гына түгел, ә башка айларда да ач
булган кешеләрнең сыкрануларын һәм газапларын
үзебезнекедәй кабул итәбез. Без Галәмнәрнең Хуҗасыннан
Газа төбәге халкының газапларын җиңеләйтүен һәм изге җирдә
тынычлык урнаштыруын сорап, дога кылабыз.

Махсус хәрби операция кырында илебез мәнфәгатьләре, Ватаныбыз иминлеге өчен көрәш дәвам итә. Бу халкыбыз өчен, аерым алганда, безнең хәрбиләребез өчен зур сынау, аларны Аллаһы Раббыбыз ярдәменнән ташламасын.

Бу Рамазан һәм Ураза бәйрәме безнең күңелләребездә хакыйкать һәм гаделлек өстенлек итәчәгенә якты өметләрне арттырсын иде. Аллаһы Тәгалә Үзенең Китабында әйткән:

وَقُلْ جَاءَ الْحَقُّ وَزَهَقَ الْبَاطِلُ ۚ إِنَّ الْبَاطِلَ كَانَ زَهُوقًا

Әйт: ***«Хаклык килде, ялган юкка чыкты. Чөнки хаклык янында ялган бетә торган»*** (*«Әл-Исра» сүрәсе, 81 а.*).

Хөрмәтле кардәшләр, Галәмнәрнең Хуҗасы Аллаһы Раббыбыздан җир йөзендәге мөселманнарның йортларында тынычлык, иминлек, үзара аңлашу хөкем сөрүен, хәзерге вакытта мохтаҗлык һәм газап кичерүчеләргә җиңеллек бирүен, авыруларга дәвасын, бу айны мөселман буларак, догада үткәргән колларына киләсе Рамазанны да саулыкта каршы алдыруын сорап, дога кылабыз. Әмиин!

والسلام عليكم ورحمة الله وبركاته

***Ихтирам белән һәм сезнең өчен догада калып,***

***мөфти шәех Равил Гайнетдин,***

*Россия Федерациясе мөселманнары*
*Диния нәзарәте рәисе*